ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 14 » март 2023 ел № 35

**«Персональ мәгълүматлар турында» Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда, дәүләт яисә муниципаль органнар булып торучы операторлар тарафыннан каралган вазыйфаларны үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 21 мартындагы 211 номерлы карары таләпләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар хакында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының 2021елның 27 августындагы 123 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Персональ мәгълүматлар турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 30 статьясындагы ундүртенче өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 14 июлендәге 266-ФЗ номерлы, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. «Персональ мәгълүматлар турында» Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда, дәүләт яисә муниципаль органнар булып торучы операторлар тарафыннан каралган вазыйфаларны үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 21 мартындагы 211 номерлы карары таләпләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар хакында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының 2021елның 27 августындагы 123 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советында персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләренең «Гомуми нигезләмәләр» дигән 2 бүлегенең 12 нче абзацында түбәндәге эчтәлекле яңа җөмлә өстәргә:

«Совет персональ мәгълүматларны чит ил физик затына яисә чит ил юридик затына эшкәртүне йөкләгән очракта, күрсәтелгән затларның гамәлләре өчен

персональ мәгълүматлар субъекты алдында Совет һәм Совет күрсәтмәсе буенча персональ мәгълүматларны эшкәртүче зат җаваплы була».

2) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советында персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләренең «Персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре» дигән 4 бүлегенең 32 нче абзацына түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар өстәргә:

«Персональ мәгълүматлар субъектларының хокукларын бозуга китергән персональ мәгълүматларны хокуксыз яисә очраклы тапшыру (бирү, тарату, керү) факты ачыкланган очракта, Совет мондый хәлне Совет, персональ мәгълүматлар субъектларының хокукларын яклау буенча вәкаләтле орган яисә башка кызыксынган зат ачыклаган вакыттан соң, персональ мәгълүматлар субъектларының хокукларын яклау буенча вәкаләтле органга түбәндәгечә хәбәр итәргә тиеш:

1) егерме дүрт сәгать эчендә булган вакыйга турында, персональ мәгълүмат субъектларының хокукларын бозуга китерергә мөмкин сәбәпләр һәм персональ мәгълүматлар субъектларның хокукларына салынган зыян турында, тиешле вакыйганың нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар күрү турында, шулай ук Совет тарафыннан персональ мәгълүматлар субъектлары хокукларын яклау буенча вәкаләтле орган белән үзара бәйләнештә торучы вәкаләтле зат турында ачыкланган вакыйга белән бәйле сораулар буенча мәгълүматлар бирергә;

2) ачыкланган инцидентны эчке тикшерү нәтиҗәләре турында җитмеш ике сәгать эчендә, шулай ук гамәлләре ачыкланган инцидентның сәбәбе булган (булган очракта) затлар турында белешмәләр бирергә.

3) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советында персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләренең «Персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре» дигән 4 бүлегенең 36 абзацына түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«Персональ мәгълүматлар субъекты Советка персональ мәгълүматларны эшкәртүне туктату таләбе белән мөрәҗәгать иткән очракта, Совет, әлеге Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 2-11 пунктларында, 10 статьясындагы 2 өлешендә һәм 11 статьясындагы 2 өлешендә каралган очраклардан тыш, аларны эшкәртүне туктатырга яисә мондый эшкәртүне туктатуны (әгәр мондый эшкәртү персональ мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан башкарылса) тәэмин итәргә тиеш. Соратыла торган мәгълүматны бирү срогы, озайту сәбәпләрен күрсәтеп, Совет тарафыннан персональ мәгълүматлар субъектына юлланган очракта, биш эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин ".

4) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советында персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләренең «Персональ мәгълүматлар субъектларының хокуклары» дигән 6 бүлегенең 6 абзацына түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«Югарыда күрсәтелгән белешмәләр персональ мәгълүматлар субъекты яки аның вәкиле мөрәҗәгать итү яисә Совет тарафыннан персональ мәгълүматлар субъектының яисә аның вәкиленең мөрәҗәгатен алу мизгеленнән соң ун эш көне эчендә бирелә. Әлеге срок озайтылырга мөмкин, әмма соратыла торган мәгълүматны бирү срогы, озайту сәбәпләрен күрсәтеп, Совет тарафыннан

персональ мәгълүматлар субъектына җибәрелгән очракта, биш эш көненнән дә артмаска тиеш. Соратуда (запрос) персональ мәгълүматлар субъекты яки аның вәкиленең шәхесен раслаучы төп документ номеры, күрсәтелгән документны бирү датасы турында белешмәләр һәм аны бирүче орган турында белешмәләр, персональ мәгълүматлар субъектының Совет белән мөнәсәбәтләрдә катнашуын раслаучы белешмәләр (шартнамә төзү датасы, шартлы телдән билгеләнү һәм (яисә) бүтән белешмәләр булырга тиеш. Совет тарафыннан персональ мәгълүматларны эшкәртү факты персональ мәгълүматлар субъектының яки аның вәкиленең имзасы белән раслана. Сорату электрон документ рәвешендә җибәрелергә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзаланырга мөмкин. Совет югарыда күрсәтелгән белешмәләрне персональ мәгълүматлар субъектына яисә аның вәкиленә, әгәр мөрәҗәгатьтә яисә гаризада башкасы күрсәтелмәгән булса, тиешле мөрәҗәгатьне яки соратуны җибәргән рәвештә бирә".

5) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советында персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләренең «Күзәтчелек органнары соратулары очрагында гамәлләр тәртибе» дигән 7 бүлегенең 1 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«152 номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Совет күрсәтелгән орган эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны, мондый гариза алу датасыннан 10 көн эчендә, аның мөрәҗәгате буенча персональ мәгълүматлар субъектларының хокукларын яклау буенча вәкаләтле органга хәбәр итә. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин Совет тарафыннан персональ мәгълүматлар субъектларының хокукларын яклау буенча вәкаләтле орган адресына соратып алына торган мәгълүматны бирү вакытын озайту сәбәпләрен күрсәтеп, дәлилләнгән хәбәрнамә җибәрелгән очракта, биш эш көненнән дә артыгракка түгел».

6) «Персональ мәгълүматларны яшергән очракта, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының эшкәртелә торган персональ мәгълүматларны яшерү чараларын уздыру өчен җаваплы хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге»н әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

7) «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының персональ мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыру яки персональ мәгълүматлардан файдалану мөмкинлеген гамәлгә ашыру каралган хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге»н әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

8) «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы хезмәткәрләренең, персональ мәгълүматның башка субъектларының персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы»н әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

9) әлеге карарга «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы хезмәткәрләренең, шулай ук персональ мәгълүматның башка субъектларының персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы» дигән 4 нче кушымтаны 11.1 нче кушымта белән тулыландырырга.

10) әлеге карарга «Хезмәткәрнең персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы» дигән 5 нче кушымтаны 11.2 нче кушымта белән тулыландырырга.

11) әлеге карарга «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кысаларында кадрлар эшен башкару өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы хезмәткәрләренең персональ мәгълүматларын эшкәртүгә гариза-ризалыгы» дигән 6 нчы кушымтаны 13.1 нче кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru/).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советы аппараты җитәкчесе Р.Н. Галимуллинга йөкләргә.

Район башлыгы И.Г.Нуриев

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башлыгының
14 март 2023 ел, № 35
карарына 1 нче кушымта

**Арча район Советының персональ мәгълүматларны яшерү буенча чаралар үткәрү өчен җаваплы хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге**

| № т/б | Структур бүлекчә (бүлек) | Хезмәткәр вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1 | Арча район Советы | Аппарат җитәкчесе, Арча муниципаль район башлыгы ярдәмчесе |
| 2 | Арча район Советы аппаратының оештыру-гомуми бүлеге | Бүлек җитәкчесе, баш белгеч |
| 3 | Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр бүлеге | Бүлек җитәкчесе, баш белгеч |
| 4 | Арча район Советы аппаратының кадрлар секторы | Сектор мөдире, баш белгеч |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башлыгының
14 март 2023 ел, №35
карарына 2 нче кушымта

**Арча район Советының персональ мәгълүматларны эшкәртү яки персональ мәгълүматлардан файдалану мөмкинлеген гамәлгә ашыру күздә тотылган хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге**

| № т/б | Структур бүлекчә (бүлек) | Хезмәткәр вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1 | Арча район Советы | Аппарат җитәкчесе, Арча муниципаль район башлыгы ярдәмчесе |
| 2 | Арча район Советы аппаратының оештыру-гомуми бүлеге | Бүлек җитәкчесе, баш белгеч |
| 3 | Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр бүлеге | Бүлек җитәкчесе, баш белгеч |
| 4 | Арча район Советы аппаратының кадрлар секторы | Сектор мөдире, баш белгеч |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башлыгының
14 март 2023 ел, № 85
карарына 3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы хезмәткәрләренең, шулай ук персональ мәгълүматларның башка субъектларының персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы**

Арча шәһәре

Мин,_______________________________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

_____________________________________________________ адресы буенча теркәлгән
_______________________________________________________________________

Паспорт сериясе_________№________________________________________________
____________________________________________________________ бирелгән
(дата, кем тарафыннан бирелгән)

ирекле рәвештә, үз ихтыярым белән, үз мәнфәгатьләремдә 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча шәһәре, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 14 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының (алга таба - Оператор) вәкаләтле вазыйфаи затларына автоматлаштыру чараларын кулланып яисә андый чараларны кулланмыйча персональ мәгълүматлар белән башкарылган теләсә нинди гамәлне (операцияне) яисә гамәлләрне (операцияләрне), шул исәптән, түбәндәге персональ мәгълүматларны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), куллануны, тапшыруны (таратуны, ачуны, чикләүне, юк итүне, юкка чыгаруны) кертеп, эшкәртүгә ризалык бирәм:

фамилия, исем, ата исеме, туу датасы һәм урыны, гражданлык, милләт;

элеккеге фамилия, исем, ата исеме, дата, урыны һәм үзгәрү сәбәбе (үзгәргән очракта);

Россия Федерациясе халыклары телләрен һәм чит телләрне белү;

белем (кайчан һәм нинди белем бирү учреждениеләре тәмамлады, дипломнар номеры, диплом буенча әзерлек юнәлеше яисә белгечлек, диплом буенча квалификация);

югары уку йортыннан соңгы һөнәри белем (белем бирү яисә фәнни учреждениенең исеме, тәмамлану елы), гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем (кайчан бирелгән, дипломнар, аттестатлар номерлары);

хезмәт эшчәнлеге башланганнан бирле башкарыла торган эш;

Россия Федерациясе субъекты һәм (яисә) муниципаль хезмәт, дипломатик ранг, хәрби һәм (яисә) махсус исем, хокук саклау хезмәтенең класслы чины, юстициянең класслы чины (кем һәм кайчан бирелгән);

дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр һәм мактау билгеләре (кем тарафыннан бүләкләнгән һәм кайчан);

якын туганнар, шулай ук ирнең (хатынның) якын туганнарының (ата-анасы, абый-апалары,эне-сеңелләре һәм балалары) туганлык дәрәҗәсе, фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы;

якын туганнар, шулай ук ирнең (хатынның) якын туганнарының (ата-анасы, абый-апалары,эне-сеңелләре һәм балалары) туган урыннары, эш урыннары һәм йорт адреслары;

элеккеге ирләрнең (хатыннарның) фамилияләре, исемнәре, атасының исеме, туган көне, туган урыны, эш урыны һәм йорт адреслары;

чит илдә булу (кайчан, кайда, нинди максат белән);

чит илдә даими яшәүче һәм (яисә) башка дәүләткә даими яшәү урынына чыгу өчен документлар рәсмиләштерүче якын туганнар, шулай ук ирнең (хатынның) якын туганнары (ата, ана, абый-энеләр, апа-сеңелләр һәм балалар), шул исәптән элеккеге ирнең (хатынның) фамилиясе, исеме, атасының исеме, чит илдә кайсы вакыттан бирле яши;

теркәлү һәм фактта яшәү адресы;

яшәү урыны буенча теркәлү датасы;

паспорт (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән);

гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык;

телефон номеры;

хәрби бурычка мөнәсәбәт, хәрби исәпкә алу буенча белешмәләр (запаста булган гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен);

салым түләүченең идентификация номеры;

мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы номеры;

иминият полисыннан белешмәләр;

эш, хезмәт, уку чорында рәсмиләштерелгән дәүләт серенә керү (форма, номер һәм дата);

медицина учреждениесе бәяләмәсе Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә керүгә яисә аны узуга каршы килә торган авыру булу (булмау) турында;

керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

Югарыда күрсәтелгән персональ мәгълүматларны, миңа карата Россия Федерациясенең муниципаль хезмәткә (эшкә) керүгә, аны узуга һәм туктатуга (хезмәт һәм турыдан-туры бәйле мөнәсәбәтләргә) бәйле мөнәсәбәтләр өлкәсендәге законнарын үтәүне тәэмин итү, шулай ук Арча муниципаль районы Башкарма комитетына гамәлдәге законнар белән йөкләнгән вазыйфаларны гамәлгә ашыру өчен эшкәртүгә ризалык бирәм.

Минем персональ мәгълүматларны эшкәртү барышында Оператор тарафыннан Оператор хезмәткәрләренә, Операторның башка вазыйфаи затларына, башкарган вазыйфаи вазыйфалары кысаларында, тапшыру хокукы бирәм, шулай ук мин биргән персональ мәгълүматларны Оператор күрсәтмәсе буенча өченче затларга, атап әйткәндә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советына (ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитетының һәм ТР Арча муниципаль районы Советының 2022 елның 14 мартындагы килешү буенча) һәм ВТБ Банкына (ПАО) (банк чыгара торган банк карталарыннан файдаланып, хезмәткәрләргә акчалата түләү буенча предприятиегә хезмәт күрсәтүгә 23.10.2020 килешү буенча) бирергә ризалыгымны бирәм.

Ризалык гамәлдә булган вакыт: персональ мәгълүматларны эшкәртү максатларына ирешүгә яисә аларга ирешү зарурлыгы югалган вакытка кадәр.

Мин таныш:

1) персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык ирекле формада язмача гариза нигезендә кире алынырга мөмкин;

2) персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге « 152-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 2 - 11 пунктларында, 11 статьясындагы 2 өлешендә һәм 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләрдә персональ мәгълүматларны эшкәртүне дәвам итәргә хокуклы;

3) муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң (хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылганнан) персональ мәгълүматлар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советында Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган документларны саклау срогы дәвамында саклана;

4) өченче затларга карата бирелә торган персональ мәгълүматлар бары тик Арча муниципаль районы Советына законнар белән йөкләнгән функцияләрне башкару һәм үтәү максатларында гына эшкәртеләчәк.

Персональ мәгълүматларны эшкәртә башлау датасы: ______________________________
(дата)

______________________________________________
(имза)

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башлыгының
14 март 2023 ел, № 35
карарына 4 нче кушымта

Арча муниципаль районы
башлыгының
2021 елның 27 августындагы
123 номерлы карарына
11.1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы хезмәткәрләренең, шулай ук персональ мәгълүматларның башка субъектларының персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы**

Арча шәһәре

Мин,________________________________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

__________________________________________________ адресы буенча теркәлгән

__________________________________________________________________

Паспорт сериясе_________№____________бирелде__________________________________

__________________________________________________________________
(дата, кем тарафыннан бирелгән)

ирекле рәвештә, үз ихтыярым белән, үз мәнфәгатьләремдә 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча шәһәре, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 14 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының (алга таба - Оператор) вәкаләтле вазыйфаи затларына автоматлаштыру чараларын кулланып яисә андый чараларны кулланмыйча персональ мәгълүматлар белән башкарылган теләсә нинди гамәлне (операцияне) яисә гамәлләрне (операцияләрне), шул исәптән, түбәндәге персональ мәгълүматларны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), куллануны, тапшыруны (таратуны, ачуны, чикләүне, юк итүне, юкка чыгаруны) кертеп, эшкәртүгә ризалык бирәм:

фамилия, исем, ата исеме, туу датасы һәм урыны, гражданлык, милләт;

элеккеге фамилия, исем, атасының исем, дата, урыны һәм үзгәрү сәбәбе (үзгәргән очракта);

Россия Федерациясе халыклары телләрен һәм чит телләрне белү;

белем (кайчан һәм нинди белем бирү учреждениеләре тәмамлады, дипломнар номеры, диплом буенча әзерлек юнәлеше яисә белгечлек, диплом буенча квалификация);

югары уку йортыннан соңгы һөнәри белем (белем бирү яисә фәнни учреждениенең исеме, тәмамлану елы), гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем (кайчан бирелгән, дипломнар, аттестатлар номерлары);

хезмәт эшчәнлеге башланганнан бирле башкарыла торган эш;

Россия Федерациясе субъекты һәм (яисә) муниципаль хезмәт, дипломатик ранг, хәрби һәм (яисә) махсус исем, хокук саклау хезмәтенең класслы чины, юстициянең класслы чины (кем һәм кайчан бирелгән);

дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр һәм мактау билгеләре (кем тарафыннан бүләкләнгән һәм кайчан);

якын туганнар, шулай ук ирнең (хатынның) якын туганнарының (ата-анасы, абый-апалары,эне-сеңелләре һәм балалары) туганлык дәрәҗәсе, фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы;

якын туганнар, шулай ук ирнең (хатынның) якын туганнарының (ата-анасы, абый-апалары,эне-сеңелләре һәм балалары) туган урыннары, эш урыннары һәм йорт адреслары;

элеккеге ирләрнең (хатыннарның) фамилияләре, исемнәре, атасының исеме, туган көне, туган урыны, эш урыны һәм йорт адреслары;

чит илдә булу (кайчан, кайда, нинди максат белән);

чит илдә даими яшәүче һәм (яисә) башка дәүләткә даими яшәү урынына чыгу өчен документлар рәсмиләштерүче якын туганнар, шулай ук ирнең (хатынның) якын туганнары (ата, ана, абый-энеләр, апа-сеңелләр һәм балалар), шул исәптән элеккеге ирнең (хатынның) фамилиясе, исеме, атасының исеме, чит илдә кайсы вакыттан бирле яши;

теркәлү һәм фактта яшәү адресы;

яшәү урыны буенча теркәлү датасы;

паспорт (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән);

гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык;

телефон номеры;

хәрби бурычка мөнәсәбәт, хәрби исәпкә алу буенча белешмәләр (запаста булган гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен);

салым түләүченең идентификация номеры;

мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы номеры;

иминият полисыннан белешмәләр;

транспорт чараларының тиешле категорияләре белән идарә итү хокукын раслаучы документ(машина йөртүчеләр өчен);

алдан (вакытлыча) медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча (машина йөртүчеләр өчен) медицина учреждениесе бәяләмәсе.

Югарыда күрсәтелгән персональ мәгълүматларны, миңа карата Россия Федерациясенең муниципаль хезмәткә (эшкә) керүгә, аны узуга һәм туктатуга (хезмәт һәм турыдан-туры бәйле мөнәсәбәтләргә) бәйле мөнәсәбәтләр өлкәсендәге законнарын үтәүне тәэмин итү, шулай ук Арча муниципаль районы Советына гамәлдәге законнар белән йөкләнгән вазыйфаларны гамәлгә ашыру өчен эшкәртүгә ризалык бирәм.

Минем персональ мәгълүматларны эшкәртү барышында Оператор тарафыннан Оператор хезмәткәрләренә, Операторның башка вазыйфаи затларына, башкарган вазыйфаи вазыйфалары кысаларында, тапшыру хокукы бирәм, шулай ук мин биргән персональ мәгълүматларны Оператор күрсәтмәсе буенча өченче затларга, атап әйткәндә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советына (ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитетының һәм ТР Арча муниципаль районы Советының 2022 елның 14 мартындагы килешү буенча) һәм ВТБ Банкына (ПАО) (банк чыгара торган банк карталарыннан файдаланып, хезмәткәрләргә акчалата түләү буенча предприятиегә хезмәт күрсәтүгә 23.10.2020 килешү буенча) бирергә ризалыгымны бирәм.

Ризалык гамәлдә булган вакыт: персональ мәгълүматларны эшкәртү максатларына ирешүгә яисә аларга ирешү зарурлыгы югалган вакытка кадәр.

Мин таныш:

1) персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык ирекле формада язмача гариза нигезендә кире алынырга мөмкин;

2) персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге « 152-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 2 - 11 пунктларында, 11 статьясындагы 2 өлешендә һәм 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләрдә персональ мәгълүматларны эшкәртүне дәвам итәргә хокуклы;

3) муниципаль хезмәттән азат ителгәннән (хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылганнан) соң персональ мәгълүматлар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советында Россия

Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган документларны саклау срогы дәвамында саклана;

4) өченче затларга карата бирелә торган персональ мәгълүматлар бары тик Арча муниципаль районы Советына законнар белән йөкләнгән функцияләрне башкару һәм үтәү максатларында гына эшкәртеләчәк.

Персональ мәгълүматларны эшкәртә башлау датасы: ______________________________
(дата)

_____________________________________________
(имза)

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башлыгының
14 март 2023 ел, № 35
карарына 5 нче кушымта

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 2 августындагы
123 номерлы карарына
11.2 нче кушымта

**Хезмәткәрнең**
**персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы**

Мин, ________________________________________________________________________________,
*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*
___________________________________________________________ адресы буенча яшәүче
паспорт сериясе ________________ номеры________________________бирелгән
____________________________________________________________________________________
*(кем һәм кайчан)*

Арча муниципаль районы Советында персональ мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм, аларга түбәндәгеләр керә:

-паспорт мәгълүматлары;
- дәүләт пенсия иминиятләштерүенең иминият таныклыгы мәгълүматлары;
- салым органында исәпкә кую турында таныклык күрсәткечләре;
- Арча муниципаль районы Советы белән минем арадагы хокук мөнәсәбәтләрен корректлы рәвештә рәсмиләштерү өчен минем хакта (операторга) кирәкле башка мәгълүматлар.

Мин персональ мәгълүматларымны түбәндәге максатларда файдалануга ризалык бирәм:
- хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәне корректлы документаль рәсмиләштерү.

Әлеге ризалык минем персональ мәгълүматларыма карата күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәкле яисә телгән теләсә нинди гамәлләрне гамәлгә ашыруга бирелә, алар, шул исәптән, югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәк (чикләүләрсез), җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), куллануны, таралышуны, аларны туктатуны, персональ мәгълүматларымны тапшыруны, шулай ук Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган персональ мәгълүматларым белән теләсә нинди башка гамәлләрне башкару.

Арча муниципаль районы Советы персональ мәгълүматларны эшкәртү персональ мәгълүматларны яклау турындагы РФ законнары нигезендә башкарыла дип гарантияли.

Килешү минем хезмәт күрсәтүләргә шартнамә төзегән мизгелдән алып гамәлдәге Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән сроклар узганчыга кадәр гамәлдә була.

Мин шуны раслыйм, шундый ризалык биргәндә, мин үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә эш итәм.

Дата			имза

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башлыгының
14 март 2023 ел, №35
карарына 6 нчы кушымта

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 27 августындагы
123 номерлы карарына
13.1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы хезмәткәрләренең «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кысаларында кадрлар эшен башкару өчен персональ мәгълүматларын эшкәртүгә**
**гариза-рөхсәте**

Мин,______________________________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
_____________________________________________________________________
адресы буенча яшәүче
шәхесне раслаучы документ: __________________________сериясе ______ номеры______________
_____________________________________________________________________ бирелгән
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

«Персональ мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, № 152-ФЗ Федераль законның 9 статьясы нигезендә Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 14 йорт адресы буенча урнашкан Арча муниципаль районы Советына һәм һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте идарәсе органына җирле үзидарә органына эшкә кергәндә минем тарафтан тапшырылган персональ мәгълүматларны автоматизация чараларын кулланып яки кулланмыйча эшкәртергә (теләсә нинди эш (операция) яки гамәлләр җыелмасы (операцияләр), җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, куллану, тапшыру (тарату, бирү, керү), блоклау, бетерү, юк итү), шул исәптән: фамилия, исем, ата исеме; элеккеге фамилия, ата исеме; җенес; гражданлык; милләт; чит телләрне һәм Россия Федерациясе халыкларының телләрен белү; белем; гыйльми дәрәҗә; өстәмә һөнәри белем; эш (белгечлек); дәүләт бүләкләре һәм башка бүләкләр, аерымлык билгеләре булу (кем бүләкләнгән һәм кайчан); эштән азат итү, кабул итү, күчерү, билгеләү турында белешмәләр; командировка, отпуск, хезмәткә сәләтсезлек турында мәгълүматлар; гаилә хәле (шул исәптән: гаилә составы, якын туганнарның туганлык дәрәҗәсе, фамилиясе, атасының исеме, туган көне, аларның эш урыны яки уку урыны); паспорт мәгълүматлары; гражданлык хәле актларын теркәү турында таныклык номеры; яшәү һәм тору урыны адресы; телефон номеры; дәүләт пенсия иминиятенең иминият таныклыгы номеры; хәрби исәпкә алу турында белешмәләр; салым түләүченең идентификационномеры; эш чоры өчен рәсмиләштерелгән дәүләт серенә керү; фотография; медицина учреждениеисе бәяләмәсе, шулай ук мин хезмет эшчәнлеген үтәү мәсьәләләренә кагылышлы һәм «Татарстан Республикасы гражданнар хезметенең кадрлар составының бердәм информацион системасы» Татарстан Республикасы информацион системасы кысаларында кадрлар эшен үтәү өчен кирәкле башка персональ мәгълүматлар.

Югарыда күрсәтелгән персональ мәгълүматларны хезмәт законнарын гамәлгә ашыруны, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын үтәүне тәэмин итү максатларында тапшырам.

Мин Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте идарәсе органының миңа медицина хезмәтен оештыру, пенсия белән тәэмин итү, спорт чараларында катнашу максатларында, башка билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт органнарына минем шәхси мәгълүматларымны бирергә хокуклы булуы белән килешәм. Югарыда күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт органнарының исеме һәм адресы Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән расланган нигезләмәләр белән билгеләнгән.

Мин таныш:

1) персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүгә кул куелган датадан җирле үзидарә органында эшләү дәверендә гамәлдә;

2) персональ мәгълүматны эшкәртү ризалыгы минем ирекле формада язма гаризам нигезендә кире кагылырга мөмкин;

3) персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, югарыда күрсәтелгән органнар «Персональ мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законның 11 статьясындагы 1 өлешенең 2-11 пунктларында, 10 статьясындагы 2 өлешендә һәм 11 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр булганда персональ мәгълүматларны эшкәртүне дәвам итәргә хокуклы;

4) хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылганнан соң, персональ мәгълүматлар гамәлдәге Россия Федерациясе законнарында каралган документлар саклау срогы дәвамында саклана.

Югарыда күрсәтелгән органнар тарафыннан минем персональ мәгълүматларны эшкәртү «Персональ мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә башкарыла.

| ________________________ | ________________________________/_______________________/ | |
|---|---|---|
| Дата | ФИАи | имза |